РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д. 1, с. Алан, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп ур., 1 нче йорт, Алан авылы, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053621 ОГРН 1061675010176 ИНН/КПП 1619004387/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№26** **«25» июль 2019 ел**

**Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге территориясендә махсус урыннар билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру һәм җиһазлау өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында»гы 2019 елның 10 июлендәге 67/516 номерлы карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге территориясендә түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:
- Алан авылы, Октябрь урамы, Алан авылы мәдәният йорты янында мәгълүмат стенды;
- Балыклы авылы, Октябрь урамы, Балыклы авылы мәдәният йорты янында мәгълүмат стенды;
- Күкчә авылы, Шоссе урамы, Күкчә авылы клубы янында мәгълүмат стенды;
- Ключище авылы, Үзәк урам, 16 номерлы йорт янында мәгълүмат стенды.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау округына җибәрергә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Алан авылы, Мәктәп урамы, 1 нче йорт, Алан авыл җирлеге хакимияте бинасы адресы буенча Алан авыл җирлеге мәгълүмат

стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Алан авыл җирлеге башлыгы Ә.Г.Хаҗиев